**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 5 декабрендәге 4293 номерлы карары**

# 2025 елда терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга чыгымнарны каплау максатыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясы, 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар турында»гы федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендәге грантлар алучыларны сайлап алуны уздыруны җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2024 елның 18 декабрендәге 3-35 номерлы «2025 елга һәм 2026 һәм 2027 елларның план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 25 маендагы 2128 номерлы «2016-2025 елларга Казан шәһәрендә терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау муниципаль программасы турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Расларга:

1.1. 2025 елда терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга чыгымнарны каплау максатыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (1 номерлы кушымта);

1.2. 2025 елда террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар тарафыннан субсидия алуга конкурс комиссиясе составын (2 номерлы кушымта).

2. Субсидия бирү буенча вәкаләтле орган итеп Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратын билгеләргә.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 15 ноябрендәге 4711 номерлы «Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар өчен 2024 елда субсидияләр алуга шәһәр конкурсы турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 5 декабрендәге
4293 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**2025 елда террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга чыгымнарны каплау максатыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге тәртип 2025 елда террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга чыгымнарны каплау максатыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү процедурасын билгели.

1.2. Әлеге Тәртипне гамәлгә ашыру максатыннан түбәндәге төшенчә кулланыла:

социаль әһәмияткә ия проект (алга таба – проект) – гражданлык җәмгыятен үстерүгә юнәлдерелгән социаль әһәмияткә ия актуаль проблемаларны хәл итүдә ярдәм күрсәтә торган, ресурслар һәм вакыт аралыгы белән чикләнгән чаралар комплексы.

1.3. Субсидия бирүнең максаты – Россиядә традицион рухи-әхлакый кыйммәтләр нигезендә халыкта террорчылык идеологиясен кабул итмәү һәм аны пропагандалауга тотрыклы рәвештә каршы торучанлык формалаштыруга юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы, муниципаль учреждениеләр булып тормаган, коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга финанс ярдәме күрсәтү.

1.4. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе – террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектны гамәлгә ашыру.

1.5. Субсидия алучылар – үз эшчәнлекләрен Казан шәһәре территориясендә гамәлгә ашыручы, юридик зат статусына ия булган, 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар турында»гы федераль закон таләпләренә туры килә торган коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар (алга таба – Субсидия алучы).

1.6. Субсидия бирү Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты (алга таба – Вәкаләтле орган) тарафыннан тиешле финанс елына Казан шәһәре Думасының Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турындагы карары белән белән каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидияләр бирү өчен бюджет чараларын алучы буларак Вәкаләтле органга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

1.7. Субсидия бирү ысулы – чыгымнарны финанслау.

Субсидия сайлап алу нәтиҗәләре буенча бирелә.

Сайлап алу ысулы – конкурс.

Финанслау чыганагы – шәһәр бюджеты акчалары.

1.8. Конкурста җиңү яулаган проектларны гамәлгә ашыру кысаларында алынган акчалар проект максатларына ирешү белән турыдан-туры бәйле булган чыгымнарны түләүгә юнәлдерелергә мөмкин, шул исәптән:

- проектны гамәлгә ашыруга җәлеп ителгән белгечләргә хезмәт хакы түләү;

- проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле җиһазлар, материаллар һәм чыгым материаллары сатып алу;

- проектны гамәлгә ашыру белән бәйле элемтә, транспорт хезмәтләре һәм биналарны арендалау өчен түләү;

- проектка мәгълүмати яктан ярдәм күрсәтү (басма продукция җитештерү һәм тарату, сайтлар һәм социаль челтәрләрдә сәхифәләр булдыру һәм аларны үстерү, реклама кампанияләре үткәрү) өчен түләү;

- проект кысаларында чаралар (семинарлар, тренинглар, конференцияләр, акцияләр һ.б.) оештыру һәм үткәрү;

- проектны гамәлгә ашыру белән турыдан-туры бәйле һәм гаризада нигезләнгән башка чыгымнар.

Субсидия акчаларын түбәндәге чараларга юнәлтү тыела:

- вәкиллек белән бәйле чыгымнар өчен түләү, шул исәптән банкетлар һәм фуршетлар оештыру;

- алкогольле продукция һәм тәмәке продукциясе сатып алу;

- штрафлар һәм пенялар түләү;

- аерым гражданнарга турыдан-туры матди ярдәм күрсәтү;

- сәяси партияләрне, кампанияләрне һәм акцияләрне, митинглар, демонстрацияләр һәм пикетлар әзерләүне һәм үткәрүне финанслау;

- яңа биналарны капиталь төзү;

- проектны гамәлгә ашыру белән турыдан-туры бәйле булмаган чыгымнарны каплау.

1.9. Субсидия Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә эшчәнлек алып бара торган коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга түбәндәге юнәлешләр буенча бирелә:

- террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә эшчәнлек;
- мәдәни-агарту һәм белем бирү юнәлешендә чаралар оештыру;
- деструктив берләшмәләргә җәлеп итүне профилактикалау;
- субсидия алучының матди-техник базасын яхшырту;
- экстремизм идеологиясенә буйсынган затларны социаль мохит шартларына җайлаштыру;
- проектларны гамәлгә ашыруда катнашкан затларны матди яктан стимуллаштыру;
- милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгыту, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яши торган Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен яклау һәм үстерү.

1.10. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы (алга таба – бердәм портал, «Интернет» челтәре) «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.

## II. Сайлап алуны уздыру тәртибе

2.1. Сайлап алу «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба – «Электрон бюджет» системасы) гамәлгә ашырыла.

2.2. «Электрон бюджет» системасыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып башкарыла.

2.3. Бюджет акчаларын төп бүлүченең, шулай ук социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыру өчен коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга субсидия бирүгә сайлап алу уздыру комиссиясенең (алга таба – Комиссия) сайлап алуда катнашучылар белән хезмәттәшлеге «Электрон бюджет» системасында электрон формадагы документлар кулланып гамәлгә ашырыла.

2.4. Сайлап алуны уздыру турында белдерү Вәкаләтле орган тарафыннан «Электрон бюджет» системасында веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә формалаштырыла, Вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, формалаштырылган көннән алып бер календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда бастырып чыгарыла һәм түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

- сайлап алу уздыру турында белдерүне бердәм порталда урнаштыру датасы;

- сайлап алуны уздыру вакыты;

- сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризаларны тапшыра башлау һәм аларны кабул итүне тәмамлау датасы, шул ук вакытта гаризаларны кабул итүнең тәмамлану көне сайлап алуны уздыру турында белдерү урнаштырылган көннән соң киләторган биш календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

- бюджет акчаларын төп бүлүченең атамасы, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

- субсидия бирү нәтиҗәсе;

- дәүләт мәгълүмат системасының «Интернет» челтәрендәге домен исеме һәм (яки) челтәр адресы – https://promote.budget.gov.ru;

- әлеге Тәртип белән билгеләнгән датага сайлап алуда катнашучы туры килергә тиешле таләпләр һәм күрсәтелгән таләпләргә туры килүне раслау өчен сайлап алуда катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлегенә карата таләпләр;

- субсидияләр алучыларның категорияләре һәм бәяләү критерийлары;

- сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризалар тапшыру тәртибе һәм аларның формасына һәм эчтәлегенә карата таләпләр;

- гаризаларны кире алу тәртибе, гаризаларны кире кайтару, шул исәптән гаризаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгеләү тәртибе, гаризаларга үзгәрешләр кертү тәртибе;

- гаризаларны карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләре;

- гаризаларны эшләп бетерү өчен кире кайтару тәртибе;

- гаризаларны кире кагу тәртибе, шулай ук аларны кире кагу өчен нигезләр турында мәгълүмат;

- бәяләү критерийларын үз эченә алган гаризаларны бәяләү тәртибе, гомуми бәяләүдә аларның әһәмияте, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бәяләүнең һәр критерие буенча тапшыру өчен кирәкле мәгълүмат, мондый мәгълүматны раслый торган белешмәләр, документлар һәм материаллар,

гаризаларны бәяләү вакыты, шулай ук Комиссиянең гаризаларны бәяләүдә катнашуы яки катнашмавы турында мәгълүмат;

- сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидия күләме, субсидия күләмен исәпләү тәртибе, сайлап алу нәтиҗәләре буенча субсидияне бүлү кагыйдәләре. Соңгысы сайлап алуда җиңүчегә (җиңүчеләргә) бирелә торган субсидиянең максималь, минималь күләмен, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең чик санын үз эченә алырга мөмкин;

- сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны уздыру турындагы белдерү нигезләмәләре буенча аңлатмалар бирү тәртибе, аңлатмалар бирүнең башлану һәм тәмамлану көне;

- сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) килешүне имзаларга тиешле вакыт аралыгы;

- сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан (баш тартканнар) дип тану шартлары;

- сайлап алуга йомгак ясау беркетмәсен (сайлап алуны уздыру нәтиҗәләре турындагы документны) бердәм порталда урнаштыру вакыты, ул сайлап алу җиңүчесен билгеләгән көннән соң килә торган 14 нче календарь көннән дә соңга калырга тиеш түгел.

2.5. Сайлап алу уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертергә кирәк булган очракта, Вәкаләтле орган әлеге үзгәрешләрне субсидияләр алучыларны сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын кабул итү тәмамлану көненә кадәр кертергә тиеш, шул ук вакытта:

2.5.1. сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризалар бирү вакыты мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән башлап гаризаларны кабул итү тәмамлану көненә кадәр кимендә 10 календарь көн тәшкил итәрлек итеп озайтылырга тиеш;

2.5.2. субсидияләр алучыларны сайлап алу ысулын үзгәртү рөхсәт ителми;

2.5.3. гаризаларны кабул итү башланган көннән соң субсидияләр алучыларны сайлап алу турындагы белдерүгә субсидияләр алучыларны сайлап алуда катнашучыларның гаризаларга үзгәрешләр кертү хокукын күздә тота торган нигезләмә кертелә;

2.5.4. субсидияләр алучыларны сайлап алуда катнашуга гариза тапшырган затларга субсидияләр алучыларны сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында, субсидияләр алучыларны сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, «Электрон бюджет» системасы аша хәбәр ителә.

2.6. Вәкаләтле орган сайлап алуны уздыруны гамәлдән чыгару хокукына ия. Ул сайлап алуны уздыруны гамәлдән чыгару турындагы белдерүне сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризалар бирү вакыты тәмамланырга кимендә бер эш көне кала «Электрон бюджет» системасында урнаштырырга тиеш.

2.7. Сайлап алуны гамәлдән чыгару турындагы белдерү порталда электрон рәвештә формалаштырыла, Вәкаләтле орган җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, «Электрон бюджет» системасында урнаштырыла һәм сайлап алуны гамәлдән чыгару сәбәпләре турында мәгълүматны үз эченә ала. Сайлап алу аны гамәлдән чыгару турындагы белдерү «Электрон бюджет» системасында урнаштырылган көннән гамәлдән чыгарылган дип санала.

Вәкаләтле органга әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максатны гамәлгә ашыру өчен җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын кире кайтарып алу сайлап алуны гамәлдән чыгару өчен сәбәп булып тора.

2.8. Сайлап алуда катнашу өчен гариза тапшырган сайлап алуда катнашучыларга сайлап алу уздыруны гамәлдән чыгару турында мәгълүмат «Электрон бюджет» системасы аша хәбәр ителә.

2.9. Сайлап алу бердәм порталда аны гамәлдән чыгару турында белдерү урнаштырылган көннән гамәлдән чыгарылган дип санала.

2.10. Әлеге пункт нигезендә сайлап алу уздыруны гамәлдән чыгару вакыты тәмамланганнан соң һәм сайлап алуда җиңүче белән килешү төзелгәнче, Вәкаләтле орган Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә каршы тора алмаслык хәл барлыкка килгән очракта гына сайлап алуны гамәлдән чыгарырга мөмкин.

2.11. Сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы гариза бирү көненә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

а) сайлап алуда катнашучы чит ил юридик заты, шул исәптән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган очракта) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда, акцияләре Россия Федерациясендә оештырылган сатуларда әйләнештә йөри

торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашуы белән гамәлгә ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

- сайлап алуда катнашучы экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

- сайлап алуда катнашучы БМО Уставының VII бүлеге белән каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары нигезендә махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар яисә массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

- сайлап алуда катнашучы әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максат өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге хокукый акты нигезендә, башка норматив хокукый актларына таянып, субсидия бирү планлаштырыла торган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан акчалар алмый;

- сайлап алуда катнашучы 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында»гы федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

- сайлап алуда катнашучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы юк яки ул Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

- сайлап алуда катнашучының Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча түләү вакыты узган бурычы, шул исәптән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты алдында акчалата йөкләмәләр буенча түләү вакыты узган (җайга салынмаган) башка бурычы юк;

- сайлап алуда катнашучыга карата үзгәртеп кору (сайлап алуда катнашучы юридик затка башка юридик затны кушу формасында үзгәртеп корудан тыш), бетерү процессы алып барылмый, банкротлык процедурасы кертелмәгән, сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган;

- дисквалификацияләнгән затлар реестрында сайлап алуда катнашучының дисквалификацияләнгән җитәкчесе, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яки баш бухгалтеры (булган очракта) турында белешмәләр юк.

2.12. Түбәндәгеләр сайлап алуда катнаша алмый:

- кулланучылар кооперативлары, аларга шул исәптән торак, торак-төзелеш һәм гараж кооперативлары, үзара иминиятләштерү җәмгыятьләре, кредит кооперативлары, прокат фондлары, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары керә;

- сәяси партияләр;

- эшләрен мөстәкыйль рәвештә җайга сала торган оешмалар;

- эш бирүчеләр берләшмәләре;

- кооперативлар берләшмәләре;

- сәүдә-сәнәгать палаталары;

- күчемсез милек хуҗалары ширкәтләре, аларга шул исәптән торак милекчеләре ширкәтләре, коммерциягә нигезләнмәгән бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре керә;

- адвокат палаталары;

- адвокат берләшмәләре;

- нотариус палаталары;

-дәүләт-иҗтимагый һәм иҗтимагый-дәүләт оешмалары (берләшмәләре), аларның территориаль (структур), шул исәптән аерым юридик затлар булып торучы бүлекчәләре (бүлекләре).

2.13. Сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы «Электрон бюджет» системасында әлеге Тәртипкә 1 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча гариза формалаштыра. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

2.13.1. Субсидия алучының хокукый статусын раслый торган документлар (мөһер (булган очракта) һәм Субсидия алучының җитәкчесе яки вәкаләтле вәкиле имзасы белән расланган):

- юридик затның уставы күчермәсе;

- юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (салым органы тарафыннан гариза тапшыру көненә 5 (биш) эш көне кала бирелә) яки юридик затның дәүләт тарафыннан теркәлүе турында салым органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган мәгълүмат;

- җитәкченең вазифага билгеләнүен раслый торган документ;

- җитәкче исеменнән эш йөртүче затның вәкаләтләрен раслый торган документ;

- баш бухгалтерның яки бухгалтерлык исәбен алып бару өчен җаваплы башка затның вәкаләтләрен раслый торган документ;

2.13.2. әлеге Тәртипкә 3 номерлы кушымта нигезендә субсидия күләмен исәпләү;

2.13.3. конкурста катнашуга гаризаны бәяләүнең һәр критерие буенча сайлап алуда катнашучы тарафыннан тәкъдим ителә торган мәгълүмат;

2.13.4. субсидия күләмен исәпләүне раслый торган документлар (прайс-битләр, коммерция буенча тәкъдимнәр, беренчел шартнамәләр яки финанслар белән тәэмин итү өчен субсидия соратыла торган чыгымнарны нигезләүче башка документлар).

2.14. Сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризаларны электрон рәвештә формалаштыру «Электрон бюджет» системасындагы веб-интерфейсның экрандагы тиешле формаларын тутыру һәм тапшырулары сайлап алуны уздыру турындагы белдерү белән каралган документларның электрон күчермәләрен (сканерлау юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларны) «Электрон бюджет» системасына кертү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Сайлап алуның бер катнашучысы тарафыннан сайлап алуда катнашу өчен бер номинация буенча бер генә гариза бирелергә мөмкин.

2.15. Сайлап алуда катнашучы гаризасы сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең яки аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

2.16. Сайлап алуда катнашучы тарафыннан имзаланган гаризага «Электрон бюджет» системасында теркәлү номеры куелган көн сайлап алуда катнашучының гариза тапшыру датасы булып санала.

2.17. Кергән гаризаларны ранжирлау тәртибе гаризаларны бәяләү нәтиҗәләре буенча алынган баллар кимүгә карап һәм, алынган баллар саны тигез булган очракта, гаризаларның керү чиратыннан чыгып билгеләнә.

2.18. Сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризаларга үзгәрешләр кертү сайлап алуда катнашучы, гаризаны кире алу турында электрон формада хәбәрнамә формалаштырып, яңа гариза тутырганнан соң гаризаларны кабул итү вакыты тәмамланган көнгә кадәр мөмкин.

2.19. Сайлап алуның теләсә кайсы катнашучысы, «Электрон бюджет» системасында субсидияләр алучыларны сайлап алуны уздыру турында белдерү урнаштырылган көннән башлап гаризалар бирү тәмамланырга кимендә өч эш

көне кала, «Электрон бюджет» системасында тиешле мөрәҗәгать формалаштыру юлы белән Вәкаләтле органга субсидияләр алучыларны сайлап алуны уздыру турында белдерү нигезләмәләрен аңлату белән бәйле өчтән артык булмаган санда сорау җибәрергә хокуклы.

2.20. Вәкаләтле орган, мөрәҗәгатькә җавап итеп, субсидияләр алучыларны сайлап алуны уздыру турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатманы күрсәтелгән белдерүдә билгеләнгән вакыт эчендә «Электрон бюджет» системасында тиешле аңлатма формалаштыру юлы белән җибәрә. Сайлап алуны уздыру турындагы белдерү нигезләмәләренең аңлатмалары аның асылын үзгәртергә тиеш түгел.

2.21. «Электрон бюджет» системасында формалаштырыла торган аңлатмадан файдалану мөмкинлеге сайлап алуның барлык катнашучыларына бирелә.

2.22. Сайлап алуда катнашучы, сайлап алуда катнашу өчен гариза тапшыру вакыты тәмамланганчы, сайлап алуда катнашу өчен гаризаны кире алырга хокуклы. Гариза кире алынган булса, сайлап алуда катнашучы гаризалар бирү өчен билгеләнгән вакыт эчендә кабат гариза бирергә хокуклы.

## III. Гаризаларны карап тикшерү һәм бәяләү тәртибе, шулай ук сайлап алу җиңүчесен (җиңүчеләрен) билгеләү

3.1. Тапшырылган гаризаларны карап тикшерү максатыннан Вәкаләтле орган тарафыннан Комиссия төзелә. Конкурс комиссиясе составы Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән раслана. Конкурс комиссиясе составына конкурс комиссиясе рәисе, конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, конкурс комиссиясе сәркатибе, конкурс комиссиясе әгъзалары керә.

3.2. Конкурс комиссиясе әгъзалары саны так булырга һәм биш кешедән дә ким булмаска тиеш.

3.3. Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, конкурс комиссиясе рәисе булмаганда, аның вазифаларын башкара.

3.4. Комиссия вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

- сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын карап тикшерү;
- гаризаларга бирелгән гомуми баллар кими бару тәртибендә аларны бәяләүнең йомгаклау рейтингын формалаштыру;
- сайлап алу җиңүчеләрен билгеләү.

3.5. Комиссия сәркатибе конкурс комиссиясе әгъзаларына конкурс комиссиясе утырышын уздыру вакыты һәм урыны турында хәбәр итә, конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләрен алып бара.

3.6. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы булып санала.

3.7. Конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы бер тавышка ия. Конкурс комиссиясе әгъзасы тавыш бирү хокукын башка затка тапшыра алмый. Тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып санала.

3.8. Субсидия алучыларны сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә билгеләнгән гаризалар тапшыру вакыты тәмамланган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, «Электрон бюджет» системасында Вәкаләтле органга, шулай ук Комиссиягә гаризаларны карап тикшерү һәм бәяләү мөмкинлеге ачыла.

Гаризаларны ачу беркетмәсе бердәм порталда автомат рәвештә формалаша, «Электрон бюджет» системасында Комиссия рәисенең (рәис урынбасарының) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана һәм, аны имзалаган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда урнаштырыла.

3.9. Сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 2.11 пункты белән каралган таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерү дәүләт мәгълүмат системалары белешмәләре нигезендә «Электрон бюджет» системасында, шул исәптән ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

«Электрон бюджет» системасында автомат рәвештә тикшерүне гамәлгә ашыру өчен техник мөмкинлек булмаган очракта, сайлап алуда катнашучының әлеге пункт таләпләренә туры килү-килмәвен раслау «Электрон бюджет» системасында веб-интерфейсның экрандагы тиешле формаларын тутыру юлы белән күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында тамгаларны сайлап алуда катнашучы тарафыннан электрон рәвештә билгеләп кую юлы белән башкарыла.

3.10. Комиссия гаризаларны ачкан көннән алып 10 эш көне эчендә аларны карап өйрәнә һәм сайлап алуда катнашучының әлеге Нигезләмәнең 2.11. пункты белән каралган таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә.

Ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында Вәкаләтле органның файдалана алу мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында, шулай ук бюджет акчаларын төп бүлүчеләр яки ведомство буйсынуындагы оешмалар

карамагында тиешле мәгълүмат булган очракта, Вәкаләтле органга сайлап алуда катнашучының әлеге Нигезләмәнең 2.11. пункты белән каралган таләпләргә туры килүен раслау максатыннан сайлап алуда катнашучыдан документлар һәм мәгълүмат тапшыруны (сайлап алуда катнашучы күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы белән тапшыру очрагыннан тыш) таләп итү тыела.

3.11. Әгәр дә гаризаны тулысынча, җентекле һәм объектив карап тикшерү максатыннан тапшырылган документларга һәм мәгълүматка аңлатма бирү өчен сайлап алуда катнашучыдан мәгълүмат һәм документлар алу зарурлыгы барлыкка килсә, Комиссия тарафыннан, сайлап алуда катнашучыдан документларга һәм мәгълүматларга карата аңлатма бирүне сорап, «Электрон бюджет» системасы аша сайлап алуда катнашучыга мөрәҗәгать юллана. Сайлап алуда катнашучы әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә соратыла торган мәгълүматны һәм документларны тиешле мөрәҗәгать юлланган көннән соң килә торган ике эш көне эчендә формалаштыра һәм «Электрон бюджет» системасына тапшыра.

Әгәр сайлап алуда катнашучы, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатькә җавап итеп, соратылган документларны һәм мәгълүматны әлеге пунктның икенче абзацы белән билгеләнгән вакытта тапшырмаса, бу хактагы мәгълүмат әлеге Тәртипнең 3.23 пункты белән каралган сайлап алуга нәтиҗәләр ясау беркетмәсендә теркәлә.

3.12. Гаризаларны карап тикшерү барышында гаризаларны эшләп бетерүгә кире кайтару өчен нигезләр ачыкланган очракта, Комиссия мондый нигезләр ачыкланган көннән алып бер эш көне эчендә, гаризаларны эшләп бетерүгә кире кайтару өчен нигезләрне, шулай ук гаризаның эшләп бетерүгә мохтаҗ нигезләмәләрен күрсәтеп, гаризаны, эшләп бетерү өчен, «Электрон бюджет» системасы аша кире кайтара.

3.13. Гаризаның формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләргә туры килмәү, орфографик һәм (яки) математик хаталар, исәпләүдәге хаталар ачыклану гаризаны эшләп бетерүгә кире кайтару өчен нигез булып тора.

3.14. Сайлап алуда катнашучы гаризаны эшләп бетерү өчен кире кайтарган көненнән соң килә торган ике эш көне эчендә «Электрон бюджет» системасы аша эшләп бетерелгән гаризаны кабат җибәрә.

3.15. Субсидия алучыларны сайлап алу сайлап алуда катнашучыларның субсидия алучылар категорияләренә һәм сайлап алуда катнашу турындагы гаризаларны бәяләү критерийларына туры килүләреннән чыгып, гаризаларны бәяләү йомгаклары буенча алынган баллар кимүгә карап һәм, алынган баллар

саны тигез булган очракта, гаризалар керү чиратына бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

3.16. Һәр критерий һәм тулаем гариза буенча сайлап алуда катнашучыга бирелә торган баллар саны Комиссиянең һәр әгъзасыннан гаризаны бәяләү нәтиҗәләре буенча алынган балларның уртача арифметик саны буларак билгеләнә. Бу очракта балларның уртача арифметик саны Комиссиянең һәр әгъзасы тарафыннан бирелгән балларны кушу һәм алга таба Комиссиянең шундый әгъзалары санына бүлү юлы белән билгеләнә.

Конкурс комиссиясе сәркатибе Комиссия әгъзаларының бәяләү ведомостьлары нигезендә карап тикшерелә торган һәр проект буенча, әлеге Тәртипкә 4 номерлы кушымтада китерелгән формага туры китереп, йомгаклау ведомостен тутыра.

Һәр проектка бирелгән баллар нигезендә проектларның гомуми рейтингы, шулай ук конкурсның һәр өстенлекле юнәлеше буенча проектлар рейтингы формалаша, соңгысында иң күп балл җыйган проектлар рейтингта иң югары урынны били.

Һәр проект өчен субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С=К\times З, \text{ биредә:}$$

С – субсидия күләме;

К – нәтиҗәлелек коэффициенты;

З – оешма тарафыннан соралган ярдәм суммасы.

Нәтиҗәлелек коэффициенты (К) түбәндәгечә исәпләнә:

$$К=Б:М, \text{ биредә:}$$

К – нәтиҗәлелек коэффициенты;

Б – проектка бәяләү критерийлары нигезендә бирелгән баллар;

М – алырга мөмкин булган максималь баллар саны.

3.17. Комиссия гаризаларда тасвирланган проектларны бәяли һәм алар буенча әлеге Тәртипкә 3 номерлы кушымтада китерелгән бәяләү критерийлары нигезендә баллар белән бәяләү системасы буенча карарлар кабул итә.

Конкурс нигезендә сайлап алуны уңышлы узган катнашучыларга бирелә:

700,0 мең сум – конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча 1 урын алган катнашучыга;

550,0 мең сум – конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча 2 урын алган катнашучыга;

450,0 мең сум – конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча 3 урын алган катнашучыга.

3.18. Карап тикшерү көненә сайлап алу уздыру турындагы белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килсә, гариза тиешенчә тутырылган дип таныла.

3.19. Гаризалар түбәндәге очракларда кире кагыла:

- сайлап алуда катнашучының Тәртипнең 2.11 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

- сайлап алу уздыру турындагы белдерүдә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган гаризаларның һәм (яки) документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

- Тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатыннан сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөреслеккә туры килмәве;

- сайлап алуда катнашучының гаризалар бирү өчен билгеләнгән көннән һәм (яки) вакыттан соң гариза тапшыруы.

3.20. Гаризаларны карап тикшерү беркетмәсе гаризаларны карап тикшерү нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә формалаштырыла, «Электрон бюджет» системасында Комиссия рәисенең (рәис урынбасарының) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана һәм, аны имзалаган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда урнаштырыла.

3.21. Ранжирлау тәртибендә иң күп балл җыйган гаризалар конкурс нигезендә сайлап алу җиңүчеләре булып таныла.

3.22. Гаризаларны бәяләү һәм карап тикшерү нәтиҗәләре нигезендә Комиссия субсидия бирү яки субсидия бирүне кире кагу турында карар кабул итә, ул нәтиҗәләр ясау беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

3.23. Сайлап алуга нәтиҗәләр ясау беркетмәсе сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) билгеләү нәтиҗәләре нигезендә автомат рәвештә бердәм порталда формалаштырыла, «Электрон бюджет» системасында Комиссия рәисенең (рәис урынбасарының) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана һәм, аны имзалаган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда урнаштырыла.

3.24. Сайлап алуга нәтиҗәләр ясау беркетмәсенә түбәндәге мәгълүмат кертелә:

- гаризаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

- гаризаларны бәяләү датасы, вакыты һәм урыны;

- гаризалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

- гаризаларны кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән гаризаларның сайлап алу уздыру турындагы белдерүнең кайсы нигезләмәләренә туры килмәвен күрсәтеп, гаризалары кире кагылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

- гаризаларны бәяләү эзлеклелеге, гаризаларны бәяләү өчен каралган һәр критерий буенча гаризаларга бирелгән күрсәткечләр, гаризаларга тәртип номерлары бирү турында гаризаларны бәяләү нәтиҗәләре нигезендә кабул ителгән карар;

- килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) атамасы һәм аңа (аларга) бирелә торган субсидиянең күләме.

3.25. Гаризаларны карап тикшерү беркетмәсенә һәм сайлап алуга нәтиҗәләр ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү ихтыяҗы барлыкка килгән очракта һәм әлеге үзгәрешләр сайлап алу нәтиҗәсенә йогынты ясамаса (техник хаталар, басма хаталар һ.б.), Вәкаләтле орган, гаризаларны карап тикшерү беркетмәсенең һәм сайлап алуга нәтиҗәләр ясау беркетмәсенең беренче версияләре имзаланган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, үзгәрешләр кертү сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге беркетмәләрнең яңа версияләрен формалаштыру юлы белән аларга тиешле үзгәрешләр кертә.

3.26. Субсидия алучыларны сайлап алу түбәндәге очракларда узмаган дип санала:

- гаризалар бирү срогы тәмамланган вакытка бер гариза да тапшырылмаган;

- гаризаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча барлык гаризалар кире кагылган.

## IV. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

4.1. Сайлап алу нәтиҗәләре буенча Вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуда җиңүче билгеләнгәннән соң, сайлап алуда җиңүче белән Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе әмерендә билгеләнгән типлаштырылган форма буенча ун календарь көн эчендә килешү төзелә.

4.2. Субсидия бирү нәтиҗәсенең конкрет күрсәткече һәм аңа ирешү вакыты килешү белән билгеләнә.

Вәкаләтле орган, субсидия бирү нәтиҗәләренең килешү белән билгеләнгән күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараның тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүне мониторинглый.

4.3. Вәкаләтле орган сайлап алуга йомгак ясау беркетмәсе имзаланган көннән алып өч эш көне эчендә «Электрон бюджет» системасында электрон формада килешү проектын формалаштыра.

4.4. Килешү түбәндәге мәҗбүри шартларны үз эченә алырга тиеш:

- югары технологияле чит ил җиһазларын, чималын һәм комплектлаучы эшләнмәләрне сатып алганда (алар белән тәэмин иткәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге акчаларны бирү нәтиҗәләренә ирешү белән бәйле хокукый акт белән билгеләнгән башка операцияләрдән тыш, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан алынган акчалар хисабына субсидия алучы тарафыннан, субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акчалар алучы башка юридик затлар тарафыннан чит ил валютасы алуны тыю;

- субсидия алучының, субсидия алучылар белән төзелгән килешүләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм аларның устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында җәмгыятьләрдән, аларның устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерция оешмаларыннан тыш) үзләренә карата Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәүне, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәүне тикшерүгә ризалыгы;

- килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирүнең мөмкин булмавына китергән бюджет акчаларын алучы буларак төп бүлүчегә бюджет йөкләмәләренең алдан билгеләнгән лимитлары киметелгән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү яки, яңа шартлар белән ризалашмаганда, килешүне өзү.

4.5. Субсидия алучы килешү формалаштырылган көннән алып өч эш көне эчендә аны «Электрон бюджет» системасында электрон имза белән имзалый.

Әгәр әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән вакыт эчендә Субсидия алучы тарафыннан килешү имзаланмаса, мондый килешү төзелмәгән дип санала, ә Субсидия алучы килешү төзүдән баш тарткан дип танылa.

4.6. Вәкаләтле орган җитәкчесе Субсидия алучы тарафыннан килешү имзаланган көннән алып ике эш көне эчендә аны «Электрон бюджет» системасында электрон имза белән имзалый. Шуннан соң гына килешү төзелгән дип санала.

4.7. Субсидияне күчерү Субсидия алучының төзелгән килешү нигезендә кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына аны төзегән көннән алып 10 эш көне эчендә бер мәртәбә түләү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.8. Юридик зат булып торган Субсидия алучыны кушу, кушылу яки үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп оештырганда, килешүгә, хокуклар күчә торган юридик затны килешүдә күрсәтеп, килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән йөкләмәдә затны алмаштыру өлешендә үзгәрешләр кертелә.

4.9. Юридик зат булып торган Субсидия алучыны бүлү, бүлеп чыгару рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук юридик зат булып торган Субсидия алучы юкка чыгарылганда яки шәхси эшмәкәр булып торган Субсидия алучының эшчәнлеге туктатылганда, килешүне берьяклы тәртиптә өзү турында хәбәрнамә һәм, Субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны күрсәтеп, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт формалаштырып, килешү өзелә.

4.10. Килешүгә өстәмә килешү, килешүне өзү турында килешү Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формаларда төзелә.

## V. Субсидия бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен контрольдә тотуны (мониторинглауны) гамәлгә ашыру турында таләпләр һәм аларны бозган өчен җаваплылык

5.1. Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Вәкаләтле орган Субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә тикшерү

үткәрә, шулай ук муниципаль финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

5.2. Субсидия алучы Вәкаләтле органга үзе тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәсенең килешүдә билгеләнгән конкрет күрсәткечләренең үтәлеше өчен җавап бирә.

5.3. Субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылганда, шул исәптән Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерү фактлары буенча шартларның үтәлмәве ачыкланган очракта, бирелгән субсидия Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән башлап 30 эш көне эчендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты кеременә тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

5.4. Акчаларны Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты керемена үз теләге белән кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә 30 көн эчендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

5.5. Бюджет акчаларын файдалануны Вәкаләтле орган контрольдә тота.

___________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 5 декабрендәге
4293 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**2025 елда террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар тарафыннан субсидия алуга конкурс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Б.Р.Алиев | конкурс комиссиясе рәисе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе |
| В.И.Яковлев | конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе урынбасары – хокук идарәсе башлыгы |
| Р.Ә.Мөхәрьямов | конкурс комиссиясе сәркатибе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә программаларны координацияләү бүлеге башлыгы |
| Конкурс комиссиясе әгъзалары: | |
| И.А.Ризванов | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы |
| И.Н.Сарманов | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының иҗтимагый оешмалар белән үзара бәйләнешләр бүлеге башлыгы |
| А.Л.Гатина | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының тел культурасы өлкәсендә милли сәясәтне гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы |
| Е.С.Ямбаршева | «Казан шәһәре иҗтимагый үзәге» муниципаль казна учреждениесе директоры |
| Е.В.Кисиль | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә программаларны координацияләү бүлеге баш белгече |

2025 елда террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга чыгымнарны каплау максатыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә 1 номерлы кушымта
(Форма)

(Оешма бланкында тутырыла)

**Конкурста катнашуга гариза**

____ елда социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан грант алу хокукына коммерциягә нигезләнмәгән социаль юнәлештәге оешмалар арасында уздырыла торган конкурста катнашуга ________________________________________________
(оешма атамасы)
гаризасын карап тикшерүне сорыйм.

Гариза тапшыру көненә оешманың ябылу яки үзгәртеп кору процессында булмавына, шулай ук вәкаләтле органның оешма эшчәнлеген туктатып тору турында гамәлдәге карары булмавына гарантия бирәм.

Кушымталар:
1. Оешманың мәгълүмати картасы ___ биттә ___ нөсхәдә.
2. Проектның мәгълүмати картасы/проектларның мәгълүмати карталары ___ биттә ___ нөсхәдә.
3. Проект сметасы/проектлар сметалары ___ биттә ___ нөсхәдә.
4. Оешма уставының таныкланган күчермәсе ___ биттә ___ нөсхәдә.
5. Оешма җитәкчесенең вәкаләтләрен раслый торган документлар.
6. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.
7. Салым органыннан соңгы хисап датасына оешманың барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларга һәм бюджеттан тыш фондларга түләү вакыты узган бурычы булмавын раслый торган белешмә.

| | | |
|---|---|---|
| ______________________________ | ______________ | ____________________ |
| (оешма җитәкчесе вазифасы атамасы) | (имза) | (инициаллар һәм фамилия) |
| Мөһер урыны | | ____________________ (дата) |

2025 елда террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга чыгымнарны каплау максатыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә 2 номерлы кушымта
(Форма)

**Конкурста катнашуга тәкъдим ителгән гаризаларны бәяләү критерийлары**

1. Сайлап алынган өстенлекле юнәлеш өчен проект нәтиҗәләренең әһәмияте:

- проект әлеге критерийга тулысынча туры килми – 0 балл;
- проект әлеге критерийга аз дәрәҗәдә туры килә – 2 балл;
- проект әлеге критерийга уртача дәрәҗәдә туры килә – 4 балл;
- проект әлеге критерийга тулысынча туры килә – 6 балл.

2. Максатчан аудиторияне колачлау:

- 100 кешегә кадәр – 0 балл;
- 101 кешедән 500 кешегә кадәр – 2 балл;
- 501 кешедән 1000 кешегә кадәр – 4 балл;
- 1000 кешедән артык – 6 балл.

3. Бурычларны хәл итү өчен ысулларның һәм инструментларның дөрес сайланган булуы:

- проект әлеге критерийга тулысынча туры килми – 0 балл;
- проект әлеге критерийга аз дәрәҗәдә туры килә – 2 балл;
- проект әлеге критерийга уртача дәрәҗәдә туры килә – 4 балл;
- проект әлеге критерийга тулысынча туры килә – 6 балл.

4. Проектның мәгълүмати яктан тәэмин ителеш дәрәҗәсе:

- юк – 0 балл;
- түбән – 2 балл;
- уртача – 4 балл;
- югары – 6 балл.

5. Проектны гамәлгә ашыруга чыгымнарның гомуми суммасында башка чыганакларның проектны финанслауда катнашу өлеше:

- 10 нан 15 процентка кадәр – 0 балл;
- 16 дан 25 процентка кадәр – 2 балл;
- 26 дан 35 процентка кадәр – 4 балл;
- 36 проценттан югары – 6 балл.

6. Конкурста катнашучының проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле тәҗрибәсе булу:

- әлеге критерийга тулысынча туры килми – 0 балл;
- әлеге критерийга аз дәрәҗәдә туры килә – 2 балл;
- әлеге критерийга уртача дәрәҗәдә туры килә – 4 балл;
- әлеге критерийга тулысынча туры килә – 6 балл.

7. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, массакүләм мәгълүмат чараларында конкурста катнашучы эшчәнлегенең әһәмияткә ия нәтиҗәләре турында мәгълүмат булу:

- әлеге критерийга тулысынча туры килми – 0 балл;
- әлеге критерийга аз дәрәҗәдә туры килә – 2 балл;
- әлеге критерийга уртача дәрәҗәдә туры килә – 4 балл;
- әлеге критерийга тулысынча туры килә – 6 балл.

8. Конкурста катнашучының Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, коммерциягә нигезләнгән һәм коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар белән үзара хезмәттәшлек тәҗрибәсе булу:

- әлеге критерийга тулысынча туры килми – 0 балл;
- әлеге критерийга аз дәрәҗәдә туры килә – 2 балл;
- әлеге критерийга уртача дәрәҗәдә туры килә – 4 балл;
- әлеге критерийга тулысынча туры килә – 6 балл.

Максималь мөмкин булган баллар саны – 48.

2025 елда террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга чыгымнарны каплау максатыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә 3 номерлы кушымта
(Форма)

**______ номерлы*________________________________________________**

**(проектның исеме)**

**гариза тәкъдим иткән конкурс катнашучысын ___________________________**

**(оешманың атамасы)**

**бәяләү ведомосте**

| **Критерий атамасы** | **Балларда бәяләү вариантлары** | **Балларда бәяләү** |
|---|---|---|
| 1. Сайлап алынган өстенлекле юнәлеш өчен проект нәтиҗәләренең әһәмияте | 0 - 2 - 4 - 6 | |
| 2. Максатчан аудиторияне колачлау | 0 - 2 - 4 - 6 | |
| 3. Бурычларны хәл итү өчен ысулларның һәм инструментларның дөрес сайланган булуы | 0 - 2 - 4 - 6 | |
| 4. Проектның мәгълүмати яктан тәэмин ителеш дәрәҗәсе | 0 - 2 - 4 - 6 | |
| 5. Проектны гамәлгә ашыруга чыгымнарның гомуми суммасында башка чыганакларның проектны финанслауда катнашу өлеше | 0 - 2 - 4 - 6 | |
| 6. Конкурста катнашучының проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле тәҗрибәсе булу | 0 - 2 - 4 - 6 | |
| 7. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, массакүләм мәгълүмат чараларында конкурста катнашучы эшчәнлегенең әһәмияткә ия нәтиҗәләре турында мәгълүмат булу | 0 - 2 - 4 - 6 | |
| 8. Конкурста катнашучының Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан | 0 - 2 - 4 - 6 | |

| Критерий атамасы | Балларда бәяләү вариантлары | Балларда бәяләү |
|---|---|---|
| дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, коммерциягә нигезләнгән һәм коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар белән үзара хезмәттәшлек тәҗрибәсе булу | | |
| Балларның гомуми суммасы | | |

Конкурс комиссиясе әгъзасы ________________ (имза) ____________________________________ (имзаның аңлатмасы)

-----------------------------

* Гариза номеры гаризалар журналындагы номер нигезендә билгеләнә.

2025 елда террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга чыгымнарны каплау максатыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә 4 номерлы кушымта
(Форма)

**________ номерлы* ________________________________________________**
**(проектның исеме)**

**____________________________________________________________________**
**(оешманың атамасы)**

**гаризаны гомуми бәяләү ведомосте**

| **Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме** | **Балларда бәяләү** |
| --- | --- |
| | |
| | |
| Проект буенча балларның гомуми суммасы | |

Конкурс комиссиясе сәркатибе __________ ______________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

----------------------------
[*] Гариза номеры гаризалар журналындагы номер нигезендә күрсәтелә.

Конкурста катнашу өчен гаризага
1 номерлы кушымта
(Форма)

**Оешманың мәгълүмати картасы**

| | |
|---|---|
| 1. Оешманың тулы атамасы | |
| 2. Оешманың кыскартылган атамасы | |
| 3. Тәкъдим ителгән проектның исеме (тәкъдим ителгән проектлар исемлеге) | |
| 4. Оешманың оештыру-хокукый формасы | |
| 5. Оешманың реквизитлары | - |
| Төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН) | |
| Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) | |
| Исәпкә кую сәбәбе коды (КПП) | |
| Икътисади эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы (ОКВЭД) | |
| 6. Оешманы иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрне башкаручы дип тану реестры номеры һәм датасы (оешма коммерциягә нигезләнмәгән оешма – иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрне башкаручы статусына ия булса) | |
| 7. Элемтә өчен мәгълүмат | - |
| юридик адрес (почта индексы белән) | |
| телефон (торак пункт коды белән) | |
| электрон почта | |
| веб-сайт (булган очракта) | |
| 8. Оешманың банк реквизитлары | - |
| банк атамасы | |
| банкның урнашу урыны (почта индексы белән) | |
| банкның тәңгәлләштерү номеры (ИНН)/исәпкә кую сәбәбе коды (КПП) | |
| корреспондент счеты | |
| банкның тәңгәлләштерү коды (БИК) | |
| исәп-хисап счеты | |
| 9. Оешма җитәкчесе | - |
| фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| җитәкче вазифасы (устав нигезендә) | |
| 10. Устав нигезендә оешма эшчәнлегенең төп максатлары (өчтән артык түгел) | |
| 11. Оешма эшчәнлеге юнәлдерелгән төп максатчан төркемнәр (өчтән артык түгел) | |

| | |
|---|---|
| 12. Соңгы ике елда алынган муниципаль грантлар турында белешмәләр (грант алу елы, грант суммасы, проектның исеме) | |
| 13. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, коммерциягә нигезләнгән һәм коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар белән хезмәттәшлек тәҗрибәсе | |
| 14. Соңгы ике елда оешма тарафыннан уңышлы гамәлгә ашырылган проектларның (өчтән артык түгел) кыскача тасвирламасы (проектның исемен, төп максатларны, проектның бюджетын, финанслау чыганакларын, ирешелгән нәтиҗәләрне күрсәтергә) | |
| 15. Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (бастырылган материалга сылтамаларны күрсәтергә), массакүләм мәгълүмат чараларында (массакүләм мәгълүмат чарасын һәм материалның басмага, эфирга чыгу вакытын күрсәтергә) оешма эшчәнлеге турында мәгълүмат булу | |

| ______________________ | ______________ | ______________________ |
|---|---|---|
| (оешма җитәкчесе вазифасы атамасы) | (имза) | (инициаллар һәм фамилия) |

Мөһер урыны

______________________
(дата)

Катнашу өчен гаризага
2 номерлы кушымта
(Форма)

**Проектның мәгълүмати картасы**

1. Грант соратыла торган проект исеме

____________________________________________________________________.

2. Проект җитәкчесе (фамилиясе, исеме, атасының исеме, телефон номеры)

____________________________________________________________________.

3. Тәкъдим ителгән проект (Казан шәһәре Башкарма комитетының конкурс уздыру, өстенлекле юнәлешләрнең исемлеген һәм конкурс комиссиясе составын раслау турындагы карары нигезендә) гамәлгә ашырылачак өстенлекле юнәлеш

____________________________________________________________________

4. Проектның максатчан төркемнәре (проект юнәлтелгән максатчан төркемнәрнең астына сызарга):

| | | |
|---|---|---|
| - балалар һәм яшүсмерләр | - яшьләр һәм студентлар | - хатын-кызлар |
| - күп балалы гаиләләр | - ятимнәр | - мигрантлар |
| - пенсионерлар | - ветераннар | - сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләр |

башкасы: ____________________________________
(күрсәтергә)

____________________________________________

5. Максатчан аудиторияне колачлау (проектта катнашучыларның якынча саны)

____________________________________________________________________

6. Проектның социаль әһәмиятен нигезләү (бер биттән артык түгел)

____________________________________________________________________

7. Проектның төп максатлары һәм бурычлары (ике биттән артык түгел)

____________________________________________________________________

8. Проектның тасвирламасы (ике биттән артык түгел)

____________________________________________________________________

9. Проектны гамәлгә ашыру чоры

____________________________________________________________________

10. Проектны гамәлгә ашыру планы

____________________________________________________________________

11. Проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә ирешү көтелә торган социаль нәтиҗә (сыйфат һәм (яки) сан күрсәткечләре; социаль проблемаларны хәл итүгә кертелгән конкрет өлеш)

____________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

12. Проектны мәгълүмати яктан тәэмин итү ______________________________

13. Проектны финанслау: _______________________________________

13.1. соратыла торган сумма (сумнарда) ___________________________;

13.2. гариза бирүче оешманың үз акчаларын да кертеп, финанслауда катнашу (сумнарда) ___________________________________________;

13.3. проектны гамәлгә ашыруның тулы бәясе (сумнарда)

______________________________________________________________.

| ________________________ | _____________ | ___________________ |
|---|---|---|
| (оешма җитәкчесе вазифасы атамасы) | (имза) | (инициаллар һәм фамилия) |

Мөһер урыны

Катнашу өчен гаризага
3 номерлы кушымта
(Форма)

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан грант хисабына**

______________________________________________________________________

**(проектның исеме)**

**проектын гамәлгә ашыруга чыгымнар**

**СМЕТАСЫ**

| Чыгымнар статьясы атамасы | Берәмлек-ләр саны | Бер берәмлек бәясе, сумнарда | Проектны гамәлгә ашыруның гомуми бәясе, сумнарда | Җәлеп ителгән акчалар күләме (булган очракта), сумнарда | Соратыла торган сумма (грант), сумнарда |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| | | | | | |
| Проект буенча барлыгы, шул исәптән | | | | | |

| ______________________________ | ______________ | ________________________ |
|---|---|---|
| (оешма җитәкчесе вазифасы атамасы) | (имза) | (инициаллар һәм фамилия) |

Мөһер урыны

| ______________________________ | ______________ | ________________________ |
|---|---|---|
| (баш бухгалтер) | (имза) | (инициаллар һәм фамилия) |

Мөһер урыны